## Туфан Миңнуллин исемендәге lll төбәкара фәнни-гамәли конференция

Балтач гимназиясенең 2нче А сыйныфы укучылары Туфан Миңнуллин исемендәге lll төбәкара фәнни-гамәли конференциядә катнашып беренче урын алып кайттылар. «Балаларыбызның иҗади сәләтләрен ачуга керткән зур хезмәте өчен сыйныф җитәкчесе Алсу Илдар кызы Хәкимҗановага, гимназия коллективына чын күңелдән рәхмәт сүзләребезне белдерәбез. Балаларыбыз Алсу Илдар кызы җитәкчелегендә сәхнә осталыгын үзләштереп кенә калмыйча, үз-үзләренә ышанырга да өйрәнделәр. Сабырлыгыгыз һәм һөнәри осталыгыгыз алдында баш иябез. Шатлыклы хисләребезне райондашларыбыз белән дә уртаклашасы килә», дип хәбәр юллыйлар безгә Балтач гимназиясендә укучыларның әти-әниләре.

